Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

27 январь 2023 ел № 1

**Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында**

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 январендәге 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы буенча Пенсия фонды бүлегенең Әлмәт районындагы Клиент хезмәте (бүлек хокукларында) 2023 елның 24 январендәге 51-34-09/156 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Әлмәт авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.
2. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авылы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2022 елның 31 январендәге 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Молодежный бистәсе, Мәктәп урамы, 3 йорт, Дербедень авылы, Совет урамы, 32А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлмәт авылы
башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Газизова

Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авылы башкарма комитетының
2023 елның 27 январендәге 1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4474,78 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,10 |
| Барлыгы | | 7793,48 |

Әлмәт авылы
башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Газизова

Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авылы башкарма комитетының
2023 елның 27 январендәге 1 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелә
торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен төрү | 2 623,44 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 851,34 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,10 |
| Барлыгы | | 7793,48 |

Әлмәт авылы
башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Газизова